**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

# О внесении изменений в Указ Президента Республики Татарстан «О мерах по усилению государственной поддержки молодых ученых в Республике Татарстан»

1. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 24 декабря 2002 года № УП-1153 «О мерах по усилению государственной поддержки молодых ученых в Республике Татарстан» (с изменениями, внесенными Указом Президента Республики Татарстан от 8 сентября 2007 года № УП-509) следующие изменения:

а) пункт 1 изложить в следующей редакции:

«1. Учредить 40 ежегодно выделяемых республиканских научных премий для поддержки молодых ученых в Республике Татарстан в размере 138 200 рублей каждая.»;

б) пункт 2 изложить в следующей редакции:

«2. Кабинету Министров Республики Татарстан:

утвердить положение о порядке присуждения республиканских научных премий для поддержки молодых ученых в Республике Татарстан;

обеспечить в установленном порядке финансирование расходов, связанных с реализацией настоящего Указа, а также принять иные решения, обеспечивающие его реализацию.».

2. Кабинету Министров Республики Татарстан привести свои акты в соответствие с настоящим Указом.

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Раис Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
30 сентября 2025 года
№ 815

| | | |
|---|---|---|
| **УКАЗ**<br>РАИСА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>РӘИСЕ<br>**УКАЗЫ** |

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында яшь галимнәргә дәүләт тарафыннан ярдәм күрсәтүне көчәйтү чаралары турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында яшь галимнәргә дәүләт тарафыннан ярдәм күрсәтүне көчәйтү чаралары турында» 2002 елның 24 декабрендәге ПУ-1153 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2007 елның 8 сентябрендәге ПУ-509 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасында яшь галимнәргә ярдәм күрсәтү өчен һәрберсе 138 200 сум күләмендә ел саен бирелә торган 40 республика фәнни премиясен гамәлгә куярга.»;

б) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

Татарстан Республикасында яшь галимнәргә ярдәм күрсәтү өчен республика фәнни премияләрен бирү тәртибе турында нигезләмәне расларга;

әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны тиешле тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган башка карарлар кабул итәргә.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үз актларын әлеге Указга туры китерергә.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ · АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2025 ел, 30 сентябрь
№ 815